# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге Коры Көрнәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

11.04.2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 11 апрелендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану турындагы мәсьәлә буенча Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлегенең Коры Көрнәле торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 2023 елның 12 октябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

-торак пункт территориясен төзекләндерү;

-ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү;

-су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

-каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 187 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 114 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 114 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлегендәге Коры Көрнәле авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип таныйрга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныйрга.

2. Сорау буенча карарны кабул ителгән дип таныырга: «Сез гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану турындагы мәсьәлә буенча Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлегенең Коры Көрнәле торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 2023 елның 12 октябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

-торак пункт территориясен төзекләндерү;

-ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү;

-су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

-каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Коры Көрнәле авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Көрнәле авыл җирлеге башлыгы — Д.Б.Казакова